ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2020 с.Старое Дрожжаное №17

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 сентябрендәге 1274 номерлы карарына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгының 2016 елның 20 гыйнварындагы 2 номерлы (2019 елның 31 маендагы 27 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**15.4 пунктында:**

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешмалар карамагындагы гражданнар оборонасының саклау корылмаларын билгеләү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә саклау, тоту;»;

алтынчы абзацны «, җир асты киңлегенең тирән биналарында һәм башка корылмаларында урнаштыру» сүзләрен өстәргә;

**15.6 пунктның икенче абзацында** «авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасысүзләренә алмаштырырга»;

**16.4 пунктының икенче абзацында** «Гражданнар оборонасы» сүзләреннән соң «, аста урнашкан биналары һәм җир асты киңлегендәге башка корылмалары» сүзләрен өстәргә;

**16.5 пунктның дүртенче абзацында** «маскировкалау буенча» сүзләрен «яктылык маскировкасы һәм башка төр маскировка буенча» сүзләренә алмаштырырга»;

**16.6 пунктының 2 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын, аеруча куркыныч һәм атом - төш куркынычы булган җитештерү объектларын һәм объектларны, гадәттән тыш куркыныч булган гидротехник корылмаларны һәм югары куркынычлы гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче, мобилизацион биремнәре (заказлары) булмаган һәм федераль башкарма хакимият органының Гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешмалар һәм гражданнар оборонасы буенча региональ һәм җирле дәрәҗәдәге чараларны үтәүне тәэмин итүче оешмалар исемлегенә кермәгән оешмалардан тыш, штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен булдыру, тәэмин итү һәм әзерләү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы М.Р. Гафаров